**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 27 июль № 545

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе филиалларында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче, 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче, 2015 ел, 13 февраль, 86 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Учреждение хезмәткәрләренең иң чик штат санын вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 1 386 728 сум күләмендәге айлык фонды белән 300 берәмлек итеп билгеләргә.».

2. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә, «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең оештыру структурасын билгеләнгән тәртиптә билгеләгәннән соң ике ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга «Татарстан Республикасында дәүләт

хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең дәүләт эшләрен башкаруына бәйле булган норматив чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 27 ноябрь, 921 нче карарына аны бу карар нигезләмәләренә туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 13 февраль, 86 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\545.docx